**ГЛАВА АМЗИНСКОГОСЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ, НУРЛАТ РАЙОНЫ,ӘМЗӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әмзә авыл җирлеге **КАРАР**

**30 нчы октябрь 2019 ел** **№5**

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлегенең салым акчаларын җыю һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Иске Рус Әмзәсе авылы гражданнары җыенын билгеләү турында карары:

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә эшен оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131 Федераль законның 25.1, 56 статьясы, Татарстан Республикасы 28.07.2004 ел, № 45 «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге Уставының 23 ст. нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әмзә авыл җирлеге башлыгы карар чыгарды:

**1.**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Рус Әмзәсе авылында үзара салым җыю һәм аны куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын Иске Татар Әмзәсе авылы,Карл Маркс урамы 29 нчы йортта урнашкан авыл мәдәният йортында 2019 нчы елның 18 нчы ноябрь көнне 15 сәгатькә билгеләргә;

**2.**Гражданнар җыенында каралачак түбәндәге көн тәртибен расларга:

- 2020 елда Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Рус Әмзәсе авылында яшәүче һәрбер балигъ яшьтәге граждан өчен үзара салым акчасы күләмен билгеләү.
- Җыелган үзара салым акчасын куллану сферасын билгелү

**3.**Карарны гражданнар җыенына кадәр 10 көн алдан Татарстан Республикасы мәгълүмат-телекоммуникация «Интернет» челтәрендәге рәсми хокукый мәгълүмат порталында, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтына куярга, Татарстан республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Рус Әмзәсе авылының мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

**4.**Карарны чыгарылган көннән гамәлгә кертергә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әмзә авыл җирлеге башлыгы: А. Ә. Насыйбуллин